| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>Старосляковского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Иске Эсләк авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
| --- | --- |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

27.10.2025 Иске Эсләк авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 12 ноябрендә 13сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән,

(I төркем инвалидлардан, 90 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ

булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау ( электротоварлар сатып алу һәм урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар);

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; халыкка су бирү (су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу; җирлекне су белән тәэмин итү (тирән насосларны сатып алу һәм ремонтлау, су үткәрү челтәрен ремонтлау, су колонкаларын ремонтлау) һәм су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар).

- торак пункт территориясен төзекләндерү (газон һәм чүп үләннәрен чабу, кешеләр иминлеге өчен куркыныч тудыручы авария хәлендәге һәм корыган агачларны кисү, юлларны кардан чистарту, трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу һәм карап тоту өчен башка чыгымнар; 1данәдә триммер, 1 электр пычкысы сатып алу; халыкка ял паркы булдыру өчен төзү материаллары сатып алу һәм башка чыгымнар;

- янгын куркынычсызлыгын булдыруның беренчел чараларын тәэмин итү: пожар машинасы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр һәм башка чыгымнар.

“КИЛЕШӘМ” “КАРШЫ”

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Иске Эсләк авылы, Клуб урамы,

1 нче йорт, авыл мәдәният йорты адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Әхмәтова

Совет Старосляковского сельского поселения Иске Әсләк авыл җирлеге Советы ИНН 1601002580 Агрызский муниципальный район Республики Татарстан Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы